Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советының илле өченче утырышы

Чыты авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

29 май, 2020 ел № 160

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 15 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр һәм төгәлләштерүләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге советы карар чыгарды:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 15 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм төгәлләштерүләрне кертергә:

1.1. Карар һәм кушымта исемендә, шулай ук 1 пункт текстында «өченче чакырылыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка житкерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов